| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН |
| --- | --- |
| Балык бистэсе | Рыбно- Слободский |
| муниципаль районы | муниципальный район |
| Корноухово авыл жирлегенен | ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ |
| БАШКАРМА КОМИТЕТЫ | Корноуховского сельского поселения |
| 422644, Корноухово, | 422644, Корноухово, |
| Совхоз урамы, 3 | ул. Совхозная, 3 |

Тел.: (84361) 27205, факс: (84361) 27205, e-mail:Kuh.RS @tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 17 августы** **Корноухово авылы** **№ 17**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җирләрдә үләнне, яфракларны яндыру урыннарын һәм алымнарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы, 2016 елның 20 сентябрендәге 390 номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Янгынга каршы режим турында" 2012 елның 20 сентябрендәге 390 номерлы, № 947 " Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге территориясендә торак пунктларның янгынга каршы тотрыклылыгын арттыру максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге торак пунктларының гомуми кулланылыштагы җирләрендә учак ягу, шулай ук якындагы саклану объектыннан 50 метр ераклыкта булган урыннарда һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренең 72.1 пунктында күрсәтелгән шартларда үлән,

яфракларны яндыру тыела.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертелгән чорда үз көчен югалтмый.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең Корноухово авылы, Совхоз урамы, 3 йорт ; Чирмешан авылы, Советлар урам, 21 йорт; Зюзино авылы, Үзэк урам, 6 йорт; Наумово авылы, Наумово урамы, 3 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районы

Корноухово авыл җирлеге Башлыгы Колчанов В.В